Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLVIII-1**

Балык Бистәсе штп. 2015 елның 3 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе
муниципаль районы Уставын кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының 87, 88, 89 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы проекты буенча 2015 елның 14 февралендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап, Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының кушымта итеп бирелә торган Уставын кабул итәргә.

2. Көчен югалткан дип танырга:

- Балык Бистәсе муниципаль район Советының 25.10.2011 ел №X-1 карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы;

- Балык Бистәсе муниципаль район Советының 05.09.2012 ел №XIX-2 «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Балык Бистәсе муниципаль район Советының 27.09.2013 ел №XXVIII-1 «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары;

- Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 12.11.2014 ел №XLI - 1 «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә, федераль законнар нигезендә үз көченә керүнең башка сроклары булган пунктлардан тыш.

4. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

5. Карарны дәүләт теркәве узганнан соң районның «Авыл офыклары» («Сельские горизонты») газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җәмәгатьчелек белән элемтәләр мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                                И.Г.Вәлиев